Мирас. 2001. - № 3 - С. 83-87

*ЛӘЛӘ МОРТАЗИНА*

**ТАТАРСТАНДА ЛИКБЕЗЛАР ЭШЧӘНЛЕГЕ**

Татар халкының иң затлы гореф-гадәтләренең берсе – гыйлем эстәү, укуга омтылыш. Шуңа күрә, татарлар Казан губернасында яшәүче халыклар арасында да, Русиядәге барлык мөселман халыклары арасында да мәгърифәт, белем дәрәҗәсе буенча беренче урында торган, дисәк, һич тә ялгышмабыз. Бу җәһәттән, Казан уку-укыту округы инспекторы Я. Д. Кобловның фикерен китерү урынлы булыр: «Русиянең шәркый өлешендә яшәүче халыклар арасында грамоталылык буенча татар-мөселманнар беренче урында торалар. Алар арасында укый-яза белүчеләрнең саны хәтта урыслар белән чагыштырганда да бик югары. Нинди генә сыйныфтан булуына карамастан, татар кешесе, һичшиксез, башлангыч дини мәгълүматка ия, татарча укый һәм яза белә»[1].

Ләкин шул ук вакытта күп кенә рәсми чыганакларда Казан губернасы халык мәгарифе буенча Русиянең башка 55 губернасы арасында бары тик 44 урында гына торган, дигән фикер үткәрелә[2]. Шул сүзләргә ияреп, димәк, татарларда да грамоталылык түбән булган, диючеләргә, академик Ә. Кәримул-лин сүзләре белән: «Казан губернасында бары тик татарлар гына яшәмәгән бит»[3], – дип җавап бирәсе килә.

Казан университеты профессоры Карл Фукс та, татарларның грамоталы булуына басым ясап, болай ди: «Читтән килгән һәрбер кешегә, һичшиксез, казан татарларында, гомумән әйткәндә, хәтта кайбер европа халыкларыннан да белемлерәк халык табу гаҗәп тоелыр. Укый һәм яза белмәгән татар кешесе үзенең якташлары тарафыннан түбәнсетеп карала һәм гражданин буларак, хөрмәткә ия була алмый»[4]. Инде шундый фикерләрдән соң кайбер совет чоры чыганакларындагы һәм архив материалларындагы «революциягә кадәр татарларда грамоталылык дәрәҗәсе 18-21% тан артмаган», дигән сүзләргә ничек карарга?«Хәтта кайбер европа халыкларыннан да белемлерәк» дип табылган татарлар турында ни өчен шулай әйтелгән? Моңа җавап итеп күп кенә сәбәпләрне китерергә мөмкин. Шулар арасында иң әһәмиятлесе – татарларның халык санын алу, ревизия кебек һәртөрле исәп-хисап актларыннан куркулары, үзләренең грамоталылыгын яшерергә яисә киметергә тырышулары[5].

Шулай итеп, алда әйтелгәннәрне истә тотып, революциягә кадәр татарларда грамоталылык, чынлап та, югары булган дип расларга тулы нигез бар. Соңгы елларда татар мәгарифе тарихын өйрәнгән Р. Әмирханов, татарларда грамоталылык дәрәҗәсе 80% тан да ким булмаган, дип билгели[6]. Бу фикергә без дә кушылабыз.

Әлеге темага бик озак сөйләшергә мөмкин булыр иде. Ләкин безнең төп максатыбыз – Татарстан территориясендә яшәүче барлык халыкларның укый-яза белмәүчелеген бетерү өчен барлыкка килгән ликбез (ликвидация безграмотности) кампаниясенең эшчәнлеген ачыкларга тырышу.

Гомумән алганда, XX йөз башында гади халыкның грамоталылык дәрәҗәсе бик үк югары булмаган. Укый-яза белмәүчеләр рәтен моңарчы белем алу мөмкинлеге булмаган ярлы халык, эшче һәм крестьяннар тәшкил иткән. Ә хәреф танымаган, хәтта үзенең исем-фамилиясен дә яза белмәгәннәр белән әллә ни ерак китеп булмый. Шуңа күрә Октябрь революциясеннән соң ил алдына иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып РСФСР халыкларының укый-яза белмәүчелеген бетерү мәсьәләсе килеп баса. Гражданнар сугышы, блокада, интервенциянең иң авыр

көннәренең берсендә, ил ач паеклар, транспорт һәм ягулык кризисы кичергән бер вакытта наданлыкка каршы (әгәр шулай әйтергә яраса) аяусыз көрәш ачыла. Бу көрәшнең нигезендә – 1919 елның 26 декабрендә РСФСР Халык Комиссарлары Советы тарафыннан кабул ителгән «РСФСР халыклары арасында укый-яза белмәүчелекне бетерү турындагы» Декрет[7]. Аның буенча 8 яшьтән 50 яшькә кадәр булган һәрбер укый-яза белмәүче кеше рус яки үзенең туган телендә грамоталылыкка өйрәнергә тиеш була. Ә грамотасыз дип нинди дә булса бер шрифтта (әйтик, гарәп яисә кириллицада) хәреф танымаучы, бөтенләй укый һәм яза белмәүче кеше санала. Әлбәттә, вакытлар үтү белән бу критерийга үзгәрешләр кертелә. Татарстан территориясендә әлеге көрәш ничегрәк барган?Кайбер архив материалларына таянып шушы сорауга җавап бирергә тырышып карыйк.

Көрәш, иң беренче чиратта, белемсезләрнең санын алу һәм аларны ликпунктларга чакыру белән башланып китә һәм тиз арада кызу темплар ала. Баштагы өч-дүрт ай эчендә ачылган ликпунктларның саны биш меңгә җитә. Шулай ук, гомумән, 1919–1920 елларда бөтен ил стихияле рәвештә ачылган шундый мәктәпләр челтәре белән каплануы мәгълүм. 1920 елның июль аенда ликбез буенча Бөтенсоюз Гадәттән тыш комиссиясе һәм аның урыннардагы бүлекчәләре оештырылу да моңа зур йогынты ясый.

Декрет кабул ителгәннән соң ук бу идеяне тормышка ашыру өчен төрле чаралар күрелә башлый. Шундыйларның беренчесе һәм иң әһәмиятлесе – ликбез атналыклары үткәрү. Мәсәлән, Буа кантоны буенча сакланган материаллардан 1920 елның 25–26 гыйнварында ук (ягъни Декрет кабул ителеп бер ай да үтмәс борын) шундый атналык үткәрелүе билгеле[8]. Гадәттән тыш комиссия үткәргән бу чараларның хәрби бурыч буларак кабул ителүе һәм аны үтәмәгән очракта катгый чаралар күрелүе (мәсәлән, азык-төлек чегыннан мәхрүм итү, кулга алу һ. б. ) әлеге эшнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуы турында сөйли[9].
Татарстанда халыкны белемгә чакыру, агитация үткәрүнең төрле формалары кулланылган. Алда искә алынган ликбез атналыклары уку өйләрендә, клубларда, мәктәпләрдә гади халыкка аң-белемнең кирәклеге турында әңгәмә, сәяси темаларга митинглар белән башланып киткән, соңыннан спектакльләр, концертлар белән дәвам иткән. Төрле темаларга лекцияләр (мәсәлән, хатын-кыз һәм җәмгыять, балалар сәламәтлеге, кул эшләре һ. б. ), актуаль темаларга матбугат материаллары уку – болар барысы да шул агитациянең үзенчәлекле формалары. «Бәхет һәм азатлыкка ирешүнең төп юлы – белем һәм грамоталылыкта»[10]. Нигезе итеп әнә шул лозунг алынган көрәшнең беренче этабы уңышлы уза: тиз арада укый-яза белмәүчеләрнең саны алына, уку өйләре, клублар, мәктәпләр эшкә җигелә, аз санда булса да уку әсбаплары, утын, керосинише кирәк-яраклар табыла. Беренче уңышлар инде 1920 елның язында ук күренә башлый. Мәсәлән, Чистай кантонында оештырылган курслар нәтиҗәләре буенча майга укучыларның яртысының алфавитны үзләштерүе, 40% ының алфавитның 2/3 сен өйрәнүе, ә 10% укучының йөгерек укуы билгеле[11].

1921 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, Татарстан Республикасында барлыгы 3. 023. 185 кеше булып, шуларның 857. 761ен укый-яза белмәүчеләр тәшкил итә. Шул елның язында 125. 155 кеше ликпунктларда укый. Боларның күпчелеге – 35 яшькә кадәргеләр[12]. Чөнки авыр икътисади хәл, кадрлар һәм уку өчен биналарның булмавы сәбәпле, наданлыкны бетерү эше этаплап алып барыла. Һәм беренче чиратта 18 яшьтән 35 яшькә кадәр булган производство һәм җәмәгать оешмалары әгъзаларын, милиция һәм Кызыл Армия сафларында хезмәт итүчеләрне укыту күздә тотыла. 1921 ел республикада ликпунктларның иң күп ачылган елы буларак тарихка кереп калган. Мәсәлән, Казанның үзендә генә дә 200, Арча кантонында 497, Лаеш кантонында 560, Минзәлә кантонында 480 ликпункт ачылырга тиеш була[13]. Ләкин кызу темплар белән башланган әлеге кампанияне коры

энтузиазм белән генә тотып торып булмый башлый. Шуның өстенә 1921 елгы ачлык, ягъни азык-төлек кризисы өстәлә. Бу мәктәпләр санының бик нык кимүенә китерә: Казан шәһәрендә бары тик 61 гомуми һәм 33 кызылармиячеләр өчен ликпункт кала[14]. Мәктәпләргә йөреш тә кими: үткән елдагы 65% тан 50% ка кала. Крестьяннарның күбесе, ачлыкны сәбәп итеп, укуга йөрүдән баш тарта. Үзен һәм гаиләсен туйдыру өчен артык икмәк кисәге табу беренче планга чыга. «Бирегез икмәк, укырбыз!» – диләр крестьяннар Арча кантонында[15]. «Башта безнең балаларыбызны укытыгыз, аннан соң безгә тотынырсыз!» – Монысы Чистай кантонында яшәүчеләр сүзе[16].

1921 елгы ачлык илнең экономикасын шул дәрәҗәдә какшата ки, хөкүмәт моңарчы үз карамагында булган халык мәгарифен бюджеттан төшереп калдырырга мәҗбүр була. Шулай итеп, башка тармаклар белән беррәттән, ликбез эше дә тулаем урыннарга тапшырыла. Шуның өстенә уку өчен әсбаплар, дәреслекләр, укытучы кадрлар аз булуын яки бөтенләй булмавын да исәпкә алсак, әлбәттә, әлеге елларда эшнең ни дәрәҗәдә авыр баруын аңларга була.

Ликбез кампаниясенең барышына комачаулык иткән тагын бер каршылык – кайбер предприятие җитәкчеләренең эшкә салкын каравы, эшчеләрне уку өчен ике сәгатькә эштән азат итәргә теләмәүләре. Мәсәлән, Крестовников-лар заводында ликпунктны бетерергә берничә көн генә калган эшчеләрне эштән азат итү фактлары билгеле[17].
Укый-яза белмәүчелекне бетерү эше бары тик 1923 елның яз айларында, халык хуҗалыгы ныгый башлагач кына җайга салына башлый. Бу вакытта инде ликбез буенча чыгымнар сметага кертелә. 1923 елда Татарстанда «Бетсен наданлык» җәмгыяте һәм аның Казанда 52, кантоннарда 273 ячейкасы оештырылу да кампаниянең үтәлешенә ярдәм итә[18].

1923 елның маенда үткәрелгән укый-яза белмәүчелекне бетерү буенча II Бөтенроссия съезды илдә грамотасызлыкны 1927 елга бетерүне күздә тота. Ләкин әлеге авыр эшне мондый аз срокларда башкарып чыгу мөмкин булмый. Шулай итеп, укый-яза белмәүчелекне бетерүнең икенче – җидееллык планы эшләнә. Аның буенча 1927–1934 елларда барлык белемсез кешеләр укуга тартылырга тиеш була.
Татарстанда 1928 елның 15 октябрендә старт алган культпоход әнә шул бурычларны күз алдында тотып оештырыла. Моңа кадәр нигездә хөкүмәт тарафыннан гына хәл ителгән ликбез мәсьәләләре хәзер тулысынча диярлек җәмәгать көчләре кулына күчә. Шулай итеп, әлеге эшкә эшче һәм крестьяннарның үз рәтләреннән, шулай ук укучы һәм студент яшьләр арасыннан яңа көчләр тартыла башлый: үзе укый-яза белгән һәрбер кеше ким дигәндә бер-ике кешене грамотага өйрәтергә тиеш була.

1928–1929 елларны ликбез кампаниясендә күтәрелеш еллары дияргә мөмкин. Чөнки бу эштәге күп кенә уңай күренешләр шушы елларга туры килә. Болар:
1) индивидуаль-төркемле укыту (индивидуально -групповое обучение) кер телә башлау. Татарстан территориясендә киң таралыш алган бу төр бигрәк тә мәктәбе булмаган кечкенә авылларда уңайлы булган, чөнки укый-яза белмәүче олы кешене күрше авылга йөреп укудан азат иткән. 2–8 кешедән торган төркемне укыту күбрәк нәтиҗәләр дә биргән.
2) ликпунктларда хатын-кызлар өчен аерым төркемнәр ачылу. Ирләр белән бергә укудан баш тарткан татар хатын-кызлары өчен бу бик мөһим булган. 1929 елда планның кантоннарда 108%, ә Казан буенча 122, 8%ка арттырып үтәлүендә шуларның роле дә зур[19].

Шул ук вакытта кайбер эшләп җиткермәгән моментлар да бар. Мәсәлән, шушы вакытка кадәр Татарстанда аз белемлеләр өчен махсус мәктәп булмаган. Әлеге хәл

ликпунктларны бетерүчеләрнең күп тә үтми алган белемнәрен оныту, ягъни рецидив күренешенә юл ачкан.
Вакытлар үтү белән ликпунктның максатлары да үзгәргән. 20 еллар башында төп бурыч – бер хәреф тә танымаган кешене элементар уку-язу техникасына һәм санауга өйрәтү булса, соңрак ныклы сәяси белем, география, тарих буенча мәгълүматлар бирү дә ликбез мәктәпләренең программасына кертелә. Шул рәвешчә, ликпункт укый-яза белүче, математиканың төп гамәлләре белән яхшы таныш булган, үз иленең һәм чит илләрнең экономикасын, тарихын һәм географиясен белгән, сәяси яктан грамоталы кешеләр хәзерләүче звенога әверелгән.

Татарстан – күпмилләтле республика. Анда, татар һәм руслардан тыш, башка милләт вәкилләре дә күп яши. Шуңа күрә башка милләтләрне укытуга да зур игътибар бирелә. Мәсәлән, 1923–24 уку елы алдыннан аз санлы милләтләр арасында укый-яза белмәүчелекне бетерү буенча өлкә методик конференциясе уздырылу, мари, мордва, чуваш, вотяклар өчен әлифба, дәреслек һәм программалар төзелү яки тәрҗемә ителү шул хакта сөйли[20]. Ләкин әлеге милләт вәкилләренең таралып яшәве сәбәпле терәк-инструктив пунктларының бөтенләй булмавы эшкә нык комачаулык иткән. Архив чыганакларын өйрәнгәндә шундый нәрсә күзгә чалынды: күп кенә материалларда мордваларның укырга йөрмәве, укуны кирәксенмәве, ә чувашларның, киресенчә, ликпунктларга бик теләп йөрүе турында әйтелә[21].

Кампания башыннан ук татарлар арасында эш алып бару мөһим эшләрнең берсе булып саналган. Алар өчен махсус татар инструкторлары хәзерләү, дәреслек һәм программалар төзү, ликбез эшенә кагылышлы материалларны тәрҗемә итү – шуның ачык мисалы. 1922 елда ук татарлар арасында ликбез үткәрү буенча махсус комиссия төзелә һәм аның эше даими рәвештә тикшерелеп тора[22]. Татарларны уку-язуга өйрәтүдә башка халыкларга хас булмаган өстәмә авырлыклар да булган. Шундыйларның берсе – алфавит алыштыру. 1927 елга кадәр гарәп шрифтында укый-яза белүче грамоталы саналса, яңалифкә күчү турындагы указ кабул ителгәннән соң күпчелек янә грамота-сызга әверелгән. Бу исә татарлар арасында укый-яза белүчеләр санын бик нык киметкән. 1939 елда латин язуын рус графикасына нигезләнгән алфавит белән алыштырганда да шул ук авырлыклар күзәтелгән.

Тагын бер авырлык – ликбез хәрәкәтен аңлап бетермәү, аңа һәртөрле комачаулык итү. Укытучы-ликвидаторларны кыйнау, дәресләрне өзү, хатыннарын укырга җибәртмәс өчен ирләрендә көнчелек хисе тудыру – шуның нәтиҗәләре[23]. Әмма күп җирләрдә крестьяннар, андыйларга каршылык күрсәтеп, тагын да теләп укый башлыйлар. Арча, Чаллы, Биектау, Азнакай, Тымытык һ. б. районнарда ликбез кампаниясенең планнан тыш арттырып үтәлүе шуны раслый. Артта калучылар рәтендә исә Лаеш, Чистай, Эл ки районнары.

Ликбез кампаниясе бик зур тырышлык, энтузиазм белән башланып китсә дә, ахырга таба анда кайбер негатив күренешләр дә урын ала башлый. Мәсәлән, ликбез мәктәпләрендә укучылар, аны бетерүчеләр санын арттырып күрсәтү, ягъни күзбуяучылык күренеше. 1931–32 уку елында Татарстан Халык мәгариф комитеты, республикада грамоталылык дәрәҗәсе 91% ка җитте, хәзер без соңгы белемсезләрне укыту белән Мәшгуль, дип белдерә. Бу, әлбәттә, чынбарлыкка туры килә алмый[24].
1941 елның март аенда республика буенча грамоталылык дәрәҗәсе 90, 4% ка җитә[25]. Шулай итеп, 40 еллар башында безнең илебездә ликбез кампаниясе үзенең эшен тәгәлләде, дип саналды. Татарстан Республикасының Милли архивында сакланган күпсанлы материаллар[26] да шуны раслый. Ләкин соңгы вакытта дөнья

күргән кайбер хезмәтләр буенча, 1941–1945 елгы Бөек Ватан сугышыннан соң да илебездә ликбез эшенең дәвам итүе мәгълүм булды. Эвакуациягә, көчләп күчереп утыртуга мәҗбүр ителгәннәр, шулай ук элек ликбез мәктәпләрен узып та, белгәннәрен онытып бетерүчеләр тәшкил иткән әлеге контингентны.

Гәрчә бу турыда кычкырып сөйләнелмәсә дә, әлеге мәсьәлә бары тик 60 еллар ахырында гына көн кадагыннан төшерелә. Татарстанда да ликбез эшенең 1940 елга төгәлләнеп җитмәвенә тагын бер дәлил – 1952–1958 елларда укый-яза белмәүчеләр һәм аз белемлеләр өчен программа һәм методик кулланмалар[27] бастырып чыгару. Инде бүген, XXI гасырга аяк баскач, ерак тарихка кереп калган ликбезларның тагын калкып чыкмавына ышаныч аз. Чөнки соңгы вакытта ил эчендәге сугышлар, хәерчелек, экономик киеренкелек аркасында бик күп балаларның мәктәпләрдә укый алмыйча урамда йөрүе, бомжга әйләнүе һ. б. тагын укый-яза белмәүче кешеләр төркемен барлыкка китерде. Тарих яңадан кабатланмас дип кем әйтер?!

## ИСКӘРМӘЛӘР

[1] Коблов Я. Д. Мечты татар-магометан о национальной общеобразовательной школе. –Казань, 1908. – С. 1.
[2] Толстяков К. Совет властеның беренче елларында Татарстанда халык мәгарифе (1917–1920) //Совет мәктәбе, 1966, № 11. – Б. 57.
[3] Каримуллин А. Г. У истоков татарской книги. – Казань, 1992. – С. 35.
[4] Фукс К. Казанские татары. – Казань: Фонд ТЯК, 1991. – С. 126.
[5] Әмирханов Р. Иманга тугрылык. – Казан, 1997. – Б. 170.
[6] Шунда ук. – Б. 170.
[7] Декреты Советской власти. Т. VII. – Москва, 1974. – С. 50.
[8] Татарстан Республикасының милли архивы (моннан соң: Милли архив): 3682 фонд, 1тупл, 38 эш. – Б. 13. (Барлык материаллар 3682 фонд, 1 тупланмадан алынды).
[9] Милли архив: 38 эш. – Б. 13.
[10] Милли архив: 44 эш. – Б. 10.
[11] Милли архив: 44 эш. – Б. 10.
[12] Милли архив: 272 эш. – Б. 32.
[13] Милли архив: 273 эш. – Б. 44.
[14] Милли архив: 273 эш. – Б. 11.
[15] Милли архив: 275 эш. – Б. 11.
[16] Милли архив: 277 эш. – Б. 34.
[17] Милли архив: 275 эш. – Б. 11.
[18] Хакимова Р. Ш. Борьба татарской партийной организации за ликвидацию неграмотнос-ти среди населения. – Борьба КПСС за развитие народного образования и культуры. – К.,1972. – С. 13.
[19] Милли архив: 1450 эш. – Б. 442.
[20] Милли архив: 865 эш. – Б. 149.
[21] Милли архив: 862 эш. – Б. 9.
[22] Милли архив: 227 эш. – Б. 5–6.
[23] Бюллетень Всесоюзного съезда по всеобучу. – 1931, № 5.
[24] Милли архив: 2007 эш. – Б. 11–12
[25] Милли архив: 2765 эш. – Б. 49, 53.
[26] Мәсәлән, районнарда укый-яза белмәүчелекне бетерү турында Дәүләт Актлары кабулителү. – 2537–2539 эшләр.
[27] Укый-яза белмәүчеләр һәм аз белемлеләр өчен программалар. – К., 1952; Укый-язабелмәүчеләрне укыту буенча инструктив-методик күрсәтмәләр. – К., 1958.